**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 29 февраль | № 122

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карары белән расланган Республика эвакуация комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 8 май, 299 нчы; 2009 ел, 19 июнь, 402 нче; 2010 ел, 8 июнь, 447 нче; 2012 ел, 29 февраль, 169 нчы; 2013 ел, 6 март, 148 нче; 2014 ел, 22 февраль, 106 нчы; 2015 ел, 3 март, 127 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Республика эвакуация комиссиясе составына, аны яңа редакциядә бәян итеп (теркәлгән), үзгәреш кертергә.

2. Түбәндәгеләр үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2009 ел, 19 июнь, 402 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2010 ел, 8 июнь, 447 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2011 ел, 17 март, 202 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26

июнь, 323 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2014 ел, 22 февраль, 106 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 3 март, 127 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2008 ел, 3 май, 299 нчы карарының 2 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2012 ел, 29 февраль, 169 нчы карарының 2 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2013 ел, 6 март, 148 нче карарының бишенче абзацы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\122.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2006 ел, 26 июнь, 323 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 29 февраль, 122 карары
редакциясендә)

Республика эвакуация комиссиясе
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Сафин Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасының транспорт һәм юл хуҗалыгы министры – комиссия рәисе |
| Орлов Андрей Николаевич | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы урынбасары – комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Суржко Николай Владимирович | Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары – комиссия рәисе урынбасары |
| Гәрәев Наил Мәҗит улы | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыру бүлеге башлыгы урынбасары – комиссия сәркатибе |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Әсәдуллин Марсель Хатыйп улы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының эшләр идарәчесе |
| Ахмадуллина Лилия Ринат кызы | Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының элемтә хезмәтләре күрсәтүне үстерү бүлеге башлыгы – хәбәр итү һәм элемтә төркеме башлыгы |
| Борһанов Эльс Ленс улы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының оештыру эшләре һәм социаль үсеш бүлеге башлыгы – эвакуацияләнә торган халыкны урнаштыруны оештыру төркеме башлыгы |

| | |
|---|---|
| Вафин Алмаз Рәшид улы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының методология һәм төзелештә бәяләр кую бүлеге башлыгы – эвакуацияләнә торган халыкның беренче чиратта тереклек эшчәнлеген тәэмин итү төркеме башлыгы |
| Исхаков Фәнис Әвгат улы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының метрология һәм техник контроль, хезмәтне саклау идарәсе башлыгы |
| Мөбәрәкшин Адель Рәфик улы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының җир, мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы – эвакуацияләнә торган халыкны исәпкә алу һәм мәгълүмат төркеме башлыгы |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча) (килешү буенча) |
| Натфуллин Дамир Данил улы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының музейлар эшен үстерү бүлеге башлыгы – мәдәни байлыкларны эвакуацияләү төркеме башлыгы |
| Сафина Дания Мидхәт кызы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының кадрлар бүлеге башлыгы – матди байлыкларны эвакуацияләүне исәпкә алу төркеме башлыгы |
| Сидоров Алексей Васильевич | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының транспорт идарәсе башлыгы – юллар һәм транспорт белән тәэмин итү төркеме башлыгы |
| Скороход Игорь Иванович | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының социаль тәэмин итү үзәге башлыгы (килешү буенча). |

F:\KARAR\2016\122-1.docx